ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2010 елның 24 ноябрендәге 1260-IV ДС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2010 елның 24 ноябрендәге 1260-IV ДС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәгә (2016 елның 21 июнендәге 1296-V ДС, 2016 елның 15 декабрендәге 1545-V ДС номерлы, 2019 елның 16 октябрендәге 98-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Аппаратның Эшләр идарәсе Дәүләт Советы депутатларын һәм Аппарат хезмәткәрләрен мәгълүмати-технологик, матди-техник, хуҗалык, транспорт, социаль-көнкүреш, мәдәни һәм медицина ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыра, дәүләт сатып алуларын, шулай ук Дәүләт Советы Аппаратының Административ регламенты һәм Аппаратның Эшләр идарәсе турындагы нигезләмә нигезендә башка функцияләрне гамәлгә ашыра.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $19^2$ пункт өстәргә:

«$19^2$. Аппаратның Финанс бүлеге Дәүләт Советы эшчәнлеген финанс яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра, Татарстан Республикасы бюджетыннан Дәүләт Советы эшчәнлеген тәэмин итүгә бүлеп бирелә торган акчалар чикләрендә Дәүләт Советы Аппаратының бюджет сметасын төзи һәм

үти, шулай ук Дәүләт Советы Аппаратының Административ регламенты һәм Аппаратның Финанс бүлеге турындагы нигезләмә нигезендә башка функцияләрне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2020 елның 17 апреле
№ 365-VI ДС